Кыштан соң яз килә. Язгы көннәр җылы, кояшлы була. Кайвакыт яңгырлар ява, күк күкри. Язын табигать матурлана. Җылы яклардан кошлар кайта. Урманнарда беренче чәчәкләр күренә.

Язгы бәйрәмнәр ? халыкара хатын-кызлар көне (8нче март), Хезмәт бәйрәме (1нче май), Җиңү көне (9нчы май).

Яздан соң җәй килә. Җәен көннәр эссе, аяз була. Җәй - ял вакыты. Укучыларның, студентларның каникуллары башлана. Алар спорт лагерларенда ял итәләр, башка шәһәрләргә, илләргә баралар

30 нчы августта Татарсанда зур бәйрәм була. Бу - Республика көне. Казанга күп кунаклар килә. Алар спорт ярышлары, концертлар карыйлар, күңелле ял итәләр.

Җәйдән соң көз килә. Көзен көннәр болытлы, яңгырлы була. Кошлар җылы якларга китәләр. Бакчаларда, кырларда уңыш җыялар.

Көзен мәктәпләрдә, училищеларда, техникумнарда, университетларда укулар башлана. 1нче сентябрь ? Белем көне. Ноябрь аенда тагын 2 бәйрәм бар. 6 нчы ноябрь - Татарстан Республикасының Конституциясе көне, ә 7 нче ноябрь - килешү көне.

2. Мин Казан университетында укыйм. Университетта без төрле телләр өйрәнәбез: рус (татар, инглиз, француз, алман, гарәп, фарсы, төрек, испан) телләре.

Татар теле дәресләрендә без яңа сүзләр өйрәнәбез, алар белән җөмләләр төзибез, татарча сөйләшәбез һәм аралашабыз, монологлар сөйлибез. Укытучы безгә төрле сораулар бирә, ә без җавап кайтарабыз.

Һәр дәрестә диярлек без күнегүләр язабыз, грамматик кагыйдәләр белән танышабыз, аларны кабатлыйбыз.

Дәресләрдә без Татарстан Республикасының дәүләт төзелеше, халыкара багланышлары, сәясәте, икътисады турында мәгълүмат алабыз. Шулай ук татар халкының тарихы, әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте, күренекле шәхесләре турында текстлар укыйбыз һәм тәрҗемә итәбез.

"Телләр белгән - илләр белгән", диләр.

3. Сабан туе элек-электән татар халкының яраткан бәйрәме. Сабан туе язгы эшләрне тәгәлләү бәйрәме. Ул, гадәттә, июнь башында үткәрелә, шимбә көндә авылларда, ә якшәмбе көнне районнарда була. 20 ? 25 июнь тирәсендә Казанда үтә.

Сабан туе Идел буенда яшәгән барлык милләтләрнең дә уртак бәйрәменә әйләнде. Анда татар халкы белән бергә рус, мари, удмурт, башкорт һәм башка халыклар да катнаша. Бәйрәмне үткәрү өчен, тигез һәм уңайлы урын сайлана. Бу урын мәйдан дип атала. Авыл халкы һәм кунаклар мәйданга бәйрәмчә киенеп, кайсы җәяү, кайсы машина белән килә.

Сабан туенда иң зур ярыш - көрәш. Татар көрәшендә сөлге тотып көрәшәләр. Һәр көрәшче сөлге белән көндәшенең биленнән урап тота һәм аны җиргә егарга тырыша. Көрәшне малайлар башлап җибәрәләр. Аннары мәйданга чиратлашып яшүсмерләр, егетләр, урта яшьләрдәге ирләр көрәшә. Көндәшен аркасына яткырган кеше җиңә. Көрәштә батыр калучыга тәкә һәм кыйммәтле бүләк бирәләр.

Сабантуйда икенче зур ярыш - ат чабышы. Атлар 5 - 8 километр ераклыктан мәйданга чабып керәләр. Иң зур бүләкләрнең берсе ат чабышында җиңүчегә бирелә. Иң арттан килгән атның хуҗасына да бүләк бирәләр, муенына яулыклар, тастымаллар бәйлиләр.

4. Мәйданда төрле халык уеннары һәм спорт ярышлары оештырыла: шома колгага менеп әтәч алу; капчык киеп йөгерү; капчык белән сугышу; чүлмәк вату; сулы чиләк-көянтә асып йөгерү; аяк бәйләп йөгерү; аркан тартышу һәм башка кызыклы уеннар. Спорт ярышлары йөгерү, биеклеккә һәм озынлыкка сикерү, волейбол, теннис буенча үткәрелә. Мәйданда артистлар да чыгыш ясый: бииләр, җырлыйлар, нәфис сүз сөйлиләр. Балалар да күңел ачалар, төрле уеннарда катнашалар.

Ярышлар һәм уеннар беткәч, кешеләр өйләренә таралалар. Һәр йортта табын әзерләнә, бәйрәм ашлары пешерелә. Кичен яшьләр өчен җыр-биюләр дәвам итә.

Сабан туе - күңелле һәм шатлыклы бәйрәм.

5. Казан - Татарстанның башкаласы

Казан - борынгы шәһәр. Ул Иделнең буенда урнашкан. Казанның мәйданы 288 кв. км. Анда 1миллионнан артык кеше яши.

Шәһәр 7 районга бүленгән: Вахитов, Совет, Киров, Мәскәү, Идел буе, Яңа Савин һәм Авиатөзелеш районнары.

Казанның үзәгендә тарихи һәйкәл - Кремль балкып тора. Биредә Президент Сарае, Сөембикә манарасы, Благовещение соборы һәм административ биналар урнашкан. Кремль каршындагы мәйданда герой?шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренә һәйкәл куелган.

Казанның Кремль урамында, иң матур биналарның берсендә Татарстан Республикасының Милли китапханәсе урнашкан. Аның каршында - 1804нче елда төзелгән мәшһүр Казан университеты. Биредә бөек ачышлар ясалган, атаклы галимнәр эшләгән. Университет - Татарстанның, Казанның горурлыгы.

Башкалабызда берсеннән-берсе матур биналар, урамнар, истәлекле һәм тарихи урыннар шактый күп. Алар арасында Дәүләт музее, Сынлы сәнгать музее, шәһәр хакимияте бинасы, опера һәм балет театры һәм башкалар.

6. Казан - эре сәнәгый үзәк. Биредә самолетлар, вертолетлар, медицина җиһазлары, магнитлы тасмалар, мех һәм тегү әйберләре, дарулар һәм башка югары сыйфатлы товарлар житештерелә. Казанда эшләнгән әйберләр төрле республикаларга, Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләренә, чит илләргә чыгарыла.

Казан - фән патшалыгы. Биредә Россия фәннәр академиясенең Казан филиалы, Татарстан фәннәр академиясе, күпсанлы фәнни-тикшеренү институтлары урнашкан. Казан дәүләт университеты, техник һәм технологик, педагогика, энергетика һәм медицина университетлары, авыл хуҗалыгы академиясе, архитектура һәм төзелеш академиясе, финанс?экономика һәм коммерция институтлары галимнәре дә фәнгә зур өлеш кертәләр. Әлеге югары уку йортларында 35 меңгә якын студент белем ала.

Казан ? танылган мәдәни үзәк. Шәһәрдә 6 театр эшли: М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театры, Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, В.Качалов исемендәге Зур рус драма театры, К.Тинчурин исемендәге татар драма һәм комедия театры, Яшь тамашачы театры, Курчак театры. Биредә С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы, Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе, "Казан" милли-мәдәни үзәге, күпсанлы мәдәният сарайлары, китапханәләр бар.

Татарстан Республикасы

Татарстан Идел буенда урнашкан. Аның мәйданы - 68 мең кв. км. Халкы - 3 миллион 700 мең кеше. Татарстанда 100дән артык милләт вәкиле яши. Татарстан Республикасы составында 43 район, 19 шәһәр, шәһәр төрендәге 22 бистә һәм 1000гә якын авыл исәпләнә. Иң зур шәһәрләр - Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Әлмәт, Чистай, Алабуга һәм башкалар. Татарстан аша 4 зур елга ага: Идел, Кама, Нократ, Агыйдел. Кечкенә елгалар һәм күлләр дә күп.

Татарстан ? эре сәнәгый үзәк. Казан шәһәрендә самолетлар, вертолетлар, медицина җиһазлары, магнитлы тасмалар, мех һәм тегү әйберләре, дарулар житештерелә. Чаллыда "КаМАЗ" йөк автомобильләре һәм "Ока" җиңел машиналары, Чистай шәһәрендә атаклы "Восток" сәгатьләре, Түбән Камада автомобиль шиннары, Яшел Үзәндә суыткычлар эшләнә. Татарстанда эшләнгән югары сыйфатлы әйберләр төрле республикаларга, Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләренә, чит илләргә чыгарыла. Республикабызга да әлеге дәүләтләрдән төрле товарлар кертелә: авыл хуҗалыгы машиналары, минераль ашламалар, төзелеш һәм юл техникасы, агач материаллары һәм башкалар.

Татарстан Россия Федерациясенең өлкәләре, БДБ дәүләтләре, Балтыйк буе илләре һәм күп кенә чит илләр белән икеяклы килешүләр төзеде һәм ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштырды. Татарстан Көнчыгыш илләре белән дә, Көнбатыш илләре белән дә багланышларны киңәйтә. Чит илләрдә Татарстанның вәкаләтле вәкиллекләре эшли. Алар чит ил кешеләренә Татарстан турында мәгълүмат җиткерәләр.

7. Бөек Болгар дәүләте Европаның көнчыгышында беренче зур дәүләт булган. 922 нче елда болгарлар ислам динен кабул иткәннәр. Бу вакыйга Болгар дәүләтенең үсешенә зур йогынты ясаган. Болгарлар башка дәүләтләр белән сәүдә иткәннәр, акча сукканнар, төрле кораллар, савыт-саба эшләгәннәр. Болгарларның үз язулары булган; фән, мәдәният; мәгариф үсеш алган.

1236 нчы елда монгол явы Болгар дәүләтен басып ала. Болгар дәүләте җимерелә һәм Алтын Урдага кертелә. Алтын Урда таркалганнан соң яңа дәүләт ? Казан ханлыгы төзелә. Биредә яшәүчеләрне Казан татарлары дип йөртә башлыйлар. Казан ханлыгы Бөек Болгарның дәвамы була. Бу чорда бик матур биналар, мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр төзелгән.

1708 нче елда Казан шәһәре Казан губернасы үзәгенә әверелә. Казан губернасы хуҗалык үсеше ягыннан Россиядә алдынгы урында торган. Икътисади тормышның нигезен авыл хуҗалыгы тәшкил иткән. XVIII нче гасырда Казанда зур остаханәләр, завод-фабрикалар барлыкка килгән. Бу чорда Казан Россиянең иң эре сәүдә үзәкләренә әверелә. Шәһәр бик тиз үсеш ала. Анда телефон үткәрелә, шәһәрнең үзәк урамнарында трамвай йөри башлый, завод-фабрикаларның саны арта, тимер юл челтәре киңәя.

8. Татар халкының традицион йолалары һәм бәйрәмнәре Идел буенда яшәгән башка күрше милләт халыклары: башкорт, чуваш, мари, удмуртлар, шулай ук көнчыгыш славяннар белән дә зур уртаклык күрсәтә.

Һәр халыкның да рухи мәдәниятендә туган тел төп урынны алып тора. Халыкның туган тел, үз ана теле сакланган очракта гына милли йөзе, гореф-гадәтләр, йолалар да саклана.

Соңгы вакытта туган телебезгә дә, борынгыдан килгән йолаларга да игътибарыбыз бик нык артты. Борынгы философ һәм "тарихның атасы" дип танылган Геродот түбәндәге фикерне әйткән: "Әгәр дөньядагы халыкларга иң яхшы йолаларны һәм гореф-гадәтләрне сайлап алырга кушсаң, игътибар белән караганнан соң, һәр халык үзенекен сайлап алыр иде, чөнки барысы да үз халыкларының яшәү рәвеше иң яхшысы дип исәпли". Моннан 25 гасыр элек әйтелгән бу фикер әле бүгенге көндә дә үзенең тирәнлеге һәм дөреслеге белән таң калдыра, һәрбер халыкның борынгы йолалары һәм борынгы ышануларына хөрмәт белән карарга кирәклеге кисәтелә кебек.

9. Болгар дәүләте Чулман һәм Идел елгалары буенда мең еллар элек барлыкка килә. Аңа хәзерге Татарстан, Чувашия, Мари-эль, Удмуртия, Башкортстанның көнбатыш, Мордовиянең көнчыгыш җирләре, Самара, Ульяновск, Пенза, Саратов, Астрахань, Волгоград, Түбән Новгород, Пермь өлкәләренең зур җирләре кергән. Аның төп өлеше безнең Татарстан республикасына туры килә.

Әкренләп шәһәрләр, авыллар төзелгән. Болгарлар башка дәүләтләр белән сәүдә иткәннәр, акча сукканнар. Авылларда игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек үсә. Болгарлар көтүлекләрдә ат, сыер, сарык, кәҗә асраганнар. Алар беркайчан да дуңгыз тотмаганнар. Болгар җирләре урманнарга, елга-күлләргә бай булган. Бу аучылык өчен зур мөмкинлекләр тудырган.

Болгарлар тимер эшен яхшы белгәннәр. Бакырдан савыт-саба: тәлинкә, касә, комганнар ясаганнар. Алтынчылар, көмешчеләр кыйммәтле ташлардан матур бизәнү әйберләре ясаган.

Болгарларның үз язулары булган, фән, мәдәният, мәгариф нык үскән. 922 нче елда Болгарлар ислам дине кабул иткәннәр. Бу дәүләтнең үсешенә тагын да ярдәм итә.

Болгар-рус бәйләнешләре һәрчак төзек булган. Моңа Болгар-Киев юлы булышкан.

10. Татарстан Республикасының климаты нигездә урта киңлекләрдәге континенталь һава массалары тәэсирендә формалаша. Гыйнварда уртача температура 14? С салкын, июльдә 19? С җылы. Еллык явым-төшем күләме 450-540 мм. Явым-төшемнең 65-70% апрель-октябрь айларына туры килә. Идел алды, Кама алды һәм Бөгелмә калкулыгындагы биек урыннарда дымлырак. Майның беренче декадасында температура 10 градустан җылырак, сентябрьнең икенче декадасында 10 градустан салкынрак булучан. Кырау төшми торган вакыт гадәттә 106-150 көнгә сузыла. Җилләр күбрәк көньяк-көнбатыштан, көньяк һәм көньяк-көнчыгыштан исә.

Республика су ресурсларына бай. Су өслегенең мәйданы 4,4 мең км$^2$(барлык территориянең 6,4%) тәшкил итә. 3 меңгә якын елга һәм инеш исәпләнә, аларның уртача тыгызлыгы 1км$^2$ җиргә - 0,46 км. Җир өслеге суларының запасы сусаклагычларда тупланган. Җир асты суларының запасы шактый: төче, аз тозлы һәм тозлы сулар; аларның бер өлеше дәвалау өчен файдалы.

Туфрак катламы төрле. Республикада территориясендә соры урман туфраклары (405 чамасы) һәм кара туфрак киң таралган. Елга үзәннәрендә аллювиаль, кара туфрак һәм сазлы туфрак. Урманнар территориясенең 17% чамасын алып тора. Иделнең сул һәм Каманың уңъягында нарат урманнары, аерым урыннарда чыршы һәм ак чыршы урманнары сакланган. Кама аръягын киңьяфраклы урманнар били

11. Ерак Африканың Замбези елгасында табигатьнең гаҗәеп могҗизасы - мәһабәт Виктория шарлавыгы бар.

Аны 1855 елда күренекле инглиз сәяхәтчесе Давид Ливингстон ача һәм Англия королевасы хөрмәтенә шулай дип атый.. Шарлавыкның киңлеге - 1800м, биеклеге - 120 м. Аның тавышы 25 километрдан да ишетел, ә су тамчыларыннан торган биек болыт 40 километрдан да күренә. Елга кыялар арасыннан үзенә юл сала. Су тамчыларында салават күпере уйный, шарлавыкның каршы ягында каньон (тирән тар үзән) стенасыннан күпләгән чишмә агып төшә. Алар өстенә яңадан-яңа су ташкыны ташланып, чишмәләрне үз артыннан ияртә. Бу шарлавыкны җирле халык, "шаулый торган төтен", ди.

Күчерә торган су күләме буенча дөньяда иң куәтле шарлавык - Төньяк Америкада Ниагара елгасындагы Ниагара шарлавыгы. Аның биеклеге - 51 м. Ә дөньяда иң биек шарлавык - көньяк Америкада Чурун елгасының югары агымы тирәсендәге Анхель шарлавыгы, аның биеклеге - 1054 м. Шарлавык 1935 елда аны ачкан очучы Анхель исеме белән аталган.

12. Идел - "зур елга", "елга"дигән сүз. Идел - Татарстанда һәм элекке СССРның Европа өлешендә иң зур һәм иң әһәмиятле елга. Аның Татарстан мәйданы аша аккан өлешенең озынлыгы - 180 чакрым. Иделнең 200 дән артык кушылдыгы бар. Сул яктан килеп кушылганнары, уңъяк кушылдыклары белән чагыштырганда , күбрәк һәм сулары да мулрак. Идел - буенда Казан, Яшел Үзән, Болгар, Тәтеш шәһәрләре, заводлар, ял йортлары, бик күп авыллар һәм пристаньнар урнашкан. Идел - тыныч һәм акрын агымлы, мул сулы елга. Аның үзәннәре бик киң. Уңъяк яры текә һәм таулы. Тау битләрендә яфраклы урманнар, куаклар үсә, җиләк-җимеш бакчалары күп. Волга атамасына килсәк, ул соңрак кына таралыш ала. Бүген Волга сүзенең килеп чыгышы турында 14-15 төрле фикер бар.

13. Кабан күле

Күп төрле легенда-риваятьләрдән кергән су чыганакларының берсе - Кабан күле. Ул өч күлне берләштерә: Түбән Кабан (Бирге), Урта Кабан (Ерак) һәм Югары Кабан (Борисково Кабаны). Күлләрнең гомуми озынлыгы -* 7,5 чакрым. Болак каналы бу күл үзәненең дәвамы булып тора.

Түбән кабан күле Казан каласының үзәк өлешенә урнашкан. Элек озынлыгы 1,8 чакрым булган, хәзерге Г.Камал исемендәге Татар академия театрын төзү нәтиҗәсендә ул 1,75 чакрымга калган. Киңлеге исә 120 метрдан алып 325 метрга җитә. Тирәнлеге 12 метр, мәйданы - 55-59 гектар чамасы. Суы кызгылт төстә, сероводород исе килеп тора. Элек күл көньяк-көнбатыш өлешеннән Болак ермагы ярдәмендә Казан суы белән тоташкан булган.

Урта Кабан - зур күл. Ул Түбән кабаннан көньякка таба урнашкан. Аның озынлыгы - 3,3 чакрым, киңлеге 170 метрдан алып 589 метрга кадәр җитә. Уртача тирәнлеге - 6,5 метр.

Югары Кабан белән Урта Кабан арасы - 1,3 чакрым. Югары Кабан күле - мөстәкыйль күл; ул башка күлләр белән тоташмаган. Аның озынлыгы - 930, киңлеге - 300 метр. Күлнең көнбатыш ярында Борисково бистәсе урнашкан, көнчыгыш ягыннан автотрасса уза. Хәзерге вакытта Кабан күленең экологик халәте катлаулы.

14. Аккош күле

Аккош күле Казан шәһәренең көнбатыш өлешендә, Киров районында урнашкан. Тирә-юне тыныч булып, янында кайчандыр аккошлар бала чыгарып яшәгәнгә күрә, ул шулай аталган. Күл һәм аның әйләнә-тирәсе - Казан халкының яратып ял итә торган урыннарының берсе. Аккош күле һәрберсенең киңлеге 20 метрга җиткән ермаклар белән тоташкан өч күл җыелмасыннан тора. Күлнең озынлыгы - 2,6 чакрым, киңлеге - 276 метр, уртача тирәнлеге - 1,1 метр, мәйданы - 42, 9 гектар. Хәзерге вакытта беренче һәм икенче күлләрне тоташтыра торган ермакның суы корыган, күп утраулар барлыкка килгән.Аның төньягындагы суы сазлыкка әйләнеп бара.
Тирән күл

Тирән күл - Казанның көнбатыш кырыеннан Осиново (Яшел Үзән р-ны) авылына таба сузылган. Ул төньяк-көнбатыштан көньяк көнчыгыш юнәлештә урнашкан; озынлыгы - 1 чакрым, киңлеге - 45 метр чамасы, мәйданы 12 гектар. Иң тирән урыны - 16 метр чамасы, уртача тирәнлеге - 6 метр. Күл төбендә карст токымнары эрү нәтиҗәсендә барлыкка килгән тирән чокырлар, упкыннар бар. Аның көньяк-көнчыгыш өлеше саерак. Күлнең бу ягында куаклыклар үсә. Күл, нигездә, аңа агып төшә торган сулар белән туклана. Шуңа күрә аның суы саргылт төстә. Болганчык су аша кояш нурлары күлнең төбенә үтеп керә алмый. Аның су температурасы плюс 6-9 градустан артмый. Хәзерге вакытта Тирән күл саега бара.

15. Зәңгәр күл

Зәңгәр күл Казан тирәсендә - Казан суы бассейнындагы Щербаковка авылы янында урнашкан. Ул урман, куаклыклар һәм сазлыклар белән әйләндереп алынган. Мәйданы - 1км$^2$ чамасы. Күлнең тирәнлеге - 2-3 метр. Бу күлнең төньяк ягында киңәеп киткән өлешендә Олы һәм Кече упкын бар. Кече упкынның тирәнлеге - 5-6 метр. Суүсемнәр басу сәбәпле, аның төбе күренми. Олы упкын - диаметры 50 метрга җитә торган түгәрәк рәвешендәге чокырны хәтерләтә. Тирәнлеге 15 метрга җитә; суы үтә күренмәле һәм бик чиста булганлыктан төбе күренеп тора. Аның формасы берсе эченә берсе куелган өч бүрәнкәне хәтерләтә. Тирә-юне гипс катламы белән әйләндереп алынган. Упкын төбендә юлы түбәнгә китә торган тар гына тишек бар. Ул тишекнең тирәнлеге 4 метр. Зәңгәр күлгә килеп кушыла торган елга-чыганаклар юк. Аның үзеннән мул сулы елгачык агып чыга. Злеге күл суының составында күп төрле эрегән химик матдәләр барлыгы ачыкланган. Аның суында, Иделнең составы белән чагыштырганда, химик матдәләр 15 тапкырга күбрәк. Зәңгәр күл суы сероводородка бай, аның суының авыруларны дәвалау өчен әһәмияте зур. Кышын катмый, даими температура саклана.

II. Темы для составления монологов (или диалогов)

1. Факультетның күренекле галимнәре.
2. Татарстан табигате.
3. Казан - Татарстанның башкаласы.
4. Химия һәм туклану.
5. Металл һәм аларның төрләре.
6. Үсемлекләр систематикасы.
7. Россиянең "Кызыл китабы".
8. Россиянең флора һ&#124 1;м фаунасы.
9. Татарстанның ландшафты.
10. Төркия.
12. Шәһәрнең (республиканың) экологик проблемалары.
13. Лондон - Бөекбританиянең башкаласы.
14. Австралия.
15. Татарстандагы тыюлыклар.
16. Татарстан Республикасы
17. Татар һәм рус халыкларының милли бәйрәмнәре
18. Татарстанның су ресурслары.
19. Казан тирәсендәге сулыклар.
20. Медицинада кулланыла торган үсемлекләр.

### 7.1. Основная литература:

Беляева И.В. Иностранный язык в профессиональной коммуникации: комплексные учебные задания [Электронный ресурс]: учебное пособие. – И.В. Беляева, Е.Ю. Нестеренко, Т.И. Сорогина. – 3 изд., стер. – М.: Флинта, 2017. – 132 с. // http://znanium.com/catalog.php?bookinfo=937882

Барышников Н.В. Основы профессиональной межкультурной коммуникации: Учебник / Н.В. Барышников. – М.: Вузовский учебник: НИЦ ИНФРА-М, 2013. – 368 с.: http://znanium.com/catalog.php?bookinfo=408974

Айдарова С.Х., Гарипова-Хасаншина В.М. Татарский язык: учебное пособие для начинающих изучать татарский язык. / С.Х. Айдарова, В.М. Гарипова-Хасаншина. – Яр Чаллы: 'Ислам нуры', 2016. – 151 с.

Гиниятуллина Л.М., Айдарова С.Х. Татарский язык в профессиональной коммуникации. Учебное пособие для русскоязычных студентов (для студентов юридического факультета) / Л.М. Гиниятуллина, С.Х. Айдарова. – Казань: изд-во 'Отечество'. – 2017. –74 с.

### 7.2. Дополнительная литература:

Черданцев А.Ф. Логико-языковые феномены в юриспруденции: Монография / А.Ф. Черданцев. – М.: Норма: НИЦ Инфра-М, 2012. – 320 с. // http://znanium.com/bookread2.php?book=258096

Нелюбин Л. Л. История науки о языке [Электронный ресурс] : учебник / Л. Л. Нелюбин, Г. Т. Хухуни. – 4-е изд., стереотип. – М. : Флинта : Наука, 2011. – 376 с. http://znanium.com/bookread.php?book=406332

Амиров К.Ф. Русско-татарский юридический словарь: ок. 10 000 слов. Под ред. Ф.А. Ганиева. – Казань: Тат.кн.изд-во, 1996. – 103 с.

Литвинов И. Л. Я начинаю говорить по-татарски. – Казань: Татарское кн. изд-во, 1994. – 320 с.

### 7.3. Интернет-ресурсы:

Единое окно доступа к образовательным ресурсам - htpp://window.edu.ru

Официальный портал мэрии Казани - www.Kzn.ru.

сайт татарской прессы - www.matbugat.ru

Сайт Язык.ru - http://yazyk.h17.ru/1_lingvistics/article2.html

унивирсальная энциклопедия "Википедия" - www.Wikipedia.ru.

Филология и лингвистика - htpp://www.filologia.su/sociolingvistika

Электронные словари - www.slovari.ru

### 8. Материально-техническое обеспечение дисциплины(модуля)

Освоение дисциплины "Татарский язык в профессиональной коммуникации" предполагает использование следующего материально-технического обеспечения:

Компьютерный класс, представляющий собой рабочее место преподавателя и не менее 15 рабочих мест студентов, включающих компьютерный стол, стул, персональный компьютер, лицензионное программное обеспечение. Каждый компьютер имеет широкополосный доступ в сеть Интернет. Все компьютеры подключены к корпоративной компьютерной сети КФУ и находятся в едином домене.

Лингафонный кабинет, представляющий собой универсальный лингафонно-программный комплекс на базе компьютерного класса, состоящий из рабочего места преподавателя (стол, стул, монитор, персональный компьютер с программным обеспечением SANAKO Study Tutor, головная гарнитура), и не менее 12 рабочих мест студентов (специальный стол, стул, монитор, персональный компьютер с программным обеспечением SANAKO Study Student, головная гарнитура), сетевого коммутатора для структурированной кабельной системы кабинета.

Лингафонный кабинет представляет собой комплекс мультимедийного оборудования и программного обеспечения для обучения иностранным языкам, включающий программное обеспечение управления классом и SANAKO Study 1200, которые дают возможность использования в учебном процессе интерактивные технологии обучения с использование современных мультимедийных средств, ресурсов Интернета.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Программный комплекс SANAKO Study 1200 дает возможность инновационного ведения учебного процесса, он предлагает широкий спектр видов деятельности (заданий), поддерживающих как практики слушания, так и тренинги речевой активности: практика чтения, прослушивание, следование образцу, обсуждение, круглый стол, использование Интернета, самообучение, тестирование. Преподаватель является центральной фигурой процесса обучения. Ему предоставляются инструменты управления классом. Он также может использовать многочисленные методы оценки достижений учащихся и следить за их динамикой. SANAKO Study 1200 предоставляет учащимся наилучшие возможности для выполнения речевых упражнений и заданий, основанных на текстах, аудио- и видеоматериалах. Вся аудитория может быть разделена на подгруппы. Это позволяет организовать отдельную траекторию обучения для каждой подгруппы. Учащиеся могут работать самостоятельно, в автономном режиме, при этом преподаватель может контролировать их действия. В состав программного комплекса SANAKO Study 1200 также входит модуль Examination Module - модуль создания и управления тестами для проверки конкретных навыков и способностей учащегося. Гибкость данного модуля позволяет преподавателям легко варьировать типы вопросов в тесте и редактировать существующие тесты.

Также в состав программного комплекса SANAKO Study 1200 также входит модуль обратной связи, с помощью которых можно в процессе занятия провести экспресс-опрос аудитории без подготовки большого теста, а также узнать мнение аудитории по какой-либо теме.

Каждый компьютер лингафонного класса имеет широкополосный доступ к сети Интернет, лицензионное программное обеспечение. Все универсальные лингафонно-программные комплексы подключены к корпоративной компьютерной сети КФУ и находятся в едином домене.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе "КнигаФонд", доступ к которой предоставлен студентам. Электронно-библиотечная система "КнигаФонд" реализует легальное хранение, распространение и защиту цифрового контента учебно-методической литературы для вузов с условием обязательного соблюдения авторских и смежных прав. КнигаФонд обеспечивает широкий законный доступ к необходимым для образовательного процесса изданиям с использованием инновационных технологий и соответствует всем требованиям новых ФГОС ВПО.

Технические средства, необходимые для проведения занятий: компьютер, средства телекоммуникации (электронная почта, выход в Интернет), сканер, принтер, ноутбук, телевизор, магнитофон.

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГОС ВПО и учебным планом по направлению 05.03.06 "Экология и природопользование" .


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Автор(ы):
Кузьмина Х.Х. ____________________
Сагдиева Р.К. ____________________
"__" _________ 201 __ г.

Рецензент(ы):
Хадиева Г.К. ____________________
"__" _________ 201 __ г.



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ